**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге составына керүче Олы Укмас торак пунктында гражданнар җыены**
**КАРАРЫ**

1 август 2023 ел №17

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Шумково авыл җирлеге составына керүче Олы Укмас авылындагы гражданнар җыены нигезендә кара кабул ителде:

1. Гражданнар җыенының 17.11.2022 №2 карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.2. Алынган үзара салым акчалары җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтелгән эш төрләре исемлегенә кертү пункты:

- Олы Укмас авылындагы юлларны ремонтлау һәм карап тоту (торак пункт чикләрендә зиратка кадәр юлны тигезләү);
- территорияне төзекләндерү (Олы Укмас авылы чүплеген рекультивацияләү).

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге торак пунктының Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Шумково авылы, Үзәк урам 4; Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Олы Укмас авылы, Үзәк урам 42, Хутор авылы, Молодежная урамы, 5 йорт; Ошняк-Качкалак, Югары урам, 5 нче йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә; һәм Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә: http:// ribnaya-sloboda.tatarstan.ru, шулай ук «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында» Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Шумково авыл җирлеге Башлыгы Л.М. Нәҗмиев